РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.08.2017 №168-п

*2016 нчы елда игенчелектә һәм терлекчелектә ярыш нәтиҗәләре турында*

2016 нчы елда игенчелек һәм терлекчелек буенча ярыш нәтиҗәләрен караганнан соң,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2016 нчы елда район хуҗалыклары арасында игенчелек һәм терлекчелек продукциясе җитештерү һәм сату буенча югары күрсәткечләргә ирешкән өчен:

- Мөхәммәтшин Зөфәр Зиннәт улы җитәкләгән “Мөхәммәтшин З.З.” (крестьян) фермер хуҗалыгына беренче урынны бирергә.

Хуҗалык сөрү җирләренең һәр гектарыннан ашлык берәмлегендә 30,0 центнер уңыш җыйнап алды. Узган ел белән чагыштырганда сөт җитештерүне 118, ит җитештерүне 103 процентка арттырды. 2016 елда барлыгы 109,9 миллион сумлык акча кереме булды, рентабельлек дәрәҗәсе 49,2% тәшкил итте. Барлык акча кеременең 98 % терлекчелек продукциясе сатуга туры килде, 1 баш шартлы терлеккә 81 мең сумлык терлекчелек продукциясе сатты.

“Мөхәммәтшин З.З.” (крестьян) фермер хуҗалыгына I дәрәҗәдәге Диплом тапшырырга, хуҗалык алдынгыларын кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләргә.

- Дәүлиев Зиннур Дәүләтнур улы җитәкләгән “Саба” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә икенче урынны бирергә.

Хуҗалык сөрү җирләренең һәр гектарыннан ашлык берәмлегендә 27,1 центнер уңыш җыйнап алды. Узган ел белән чагыштырганда сөт җитештерүне 111 процентка арттырды. 2016 елда барлыгы 568,4 миллион сумлык акча кереме булды, рентабельлек дәрәҗәсе 12,5% тәшкил итте. Барлык акча

кеременең 74 % терлекчелек продукциясе сатуга туры килде, 1 баш шартлы терлеккә 60 мең сумлык терлекчелек продукциясе сатты.

"Саба" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә II дәрәҗәдәге Диплом тапшырырга, хуҗалык алдынгыларын кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләргә.

- Талипов Марсель Хәким улы җитәкләгән "Симет" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә өченче урынны бирергә.

Хуҗалык сөрү җирләренең һәр гектарыннан ашлык бирәмлегендә 22,8 центнер уңыш җыйнап алды. Узган ел белән чагыштырганда сөт җитештерүне 114, ит җитештерүне 103 процентка арттырды. 2016 елда барлыгы 65,6 миллион сумлык акча кереме булды, рентабельлек дәрәҗәсе 30,4% тәшкил итте. Барлык акча кеременең 92 % терлекчелек продукциясе сатуга туры килде, 1 баш шартлы терлеккә 53 мең сумлык терлекчелек продукциясе сатты.

"Симет" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә III дәрәҗәдәге Диплом тапшырырга, хуҗалык алдынгыларын кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләргә.

2. Авыл хуҗалыгы өлкәсендә нәтиҗәле эшләп, югары хезмәт күрсәткечләренә ирешкән алдынгыларга "Үз һөнәренең остасы" исеме бирергә һәм бүләкләр тапшырырга:

- ДТ-75 тракторында 3988 эталон гектар эш башкарган "Нырты" авыл хуҗалыгы предприятиесе" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы Шәйдуллин Рафис Мөбәрәкҗан улына;

- МТЗ-1221 тракторында 4229 эталон гектар эш башкарган "Шытсу" авыл хуҗалыгы предприятиесе" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы Гомәров Газинур Сабит улына;

- МТЗ-1221 тракторында 3719 эталон гектар эш башкарган "Мөхәмәтшин З.З." крестьян(фермер) хуҗалыгы тракторчысы Нәҗметдинов Ризван Госам улына;

- МТЗ-1221 тракторында 3490 эталон гектар эш башкарган "Саба" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы Хаҗиев Илгиз Шамил улына;

- МТЗ-92 тракторында 2599 эталон гектар эш башкарган "Юлбат" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең "Килдебәк" бригадасы тракторчысы Рафиков Наил Нуретдин улына;

- МТЗ-82 тракторында 2433 эталон гектар эш башкарган "Саба" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең "Явлаштау" бригадасы тракторчысы Газизов Хәмит Барый улына;

- МТЗ-82 тракторында 2156 эталон гектар эш башкарган "Саба" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең "Сатыш" бүлекчәсе тракторчысы Габдрахманов Хәмит Кәримулла улына;

- Т-150 тракторында 4437 эталон гектар эш башкарган “Туган як” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы Кадыров Рамил Рамазан улына;

- GCB-531-70 төягечендә 318 смена нормасы эш башкарган “Саба” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы Нигъмәтуллин Зөлфәт Зөфәр улына;

- 5146 эталон гектар эш башкарган “Саба” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы Миннебаев Рамил Раиф улына;

- 325500 тонна-километр эш башкарган “Саба” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең “Сатыш” бүлекчәсе шоферы Миннегалиев Равил Мәүлетгали улына;

- 254522 тонна-километр эш башкарган “Игенче” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте шоферы Сөнгатов Рөстәм Рафис улына;

- барлыгы 5010 центнер сөт сауган “Саба” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең “Кибәче” бригадасы савымчысы Фәйзетдинова Фидәния Нургали кызына;

- барлыгы 3663 центнер сөт сауган “Саба” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең “Сатыш” бүлекчәсе савымчысы Хәсәнова Илсөяр Гафурбай кызына;

- барлыгы 3220 центнер сөт сауган “Нырты” авыл хуҗалыгы предприятиесе” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте савымчысы Фәләхова Гөлгенә Хатыйп кызына;

- барлыгы 3778 центнер сөт сауган “Мөхәмәтшин З.З.” (крестьян) фермер хуҗалыгы савымчысы Нәҗметдинова Рузалия Гуссам кызына;

- барлыгы 5383 центнер сөт сауган “Нырты” авыл хуҗалыгы предприятиесе” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте робот фермасы операторы Кәримуллин Илнур Маннур улына;

- үзенә беркетелгән 56 баш терлектән 178 центнер тулаем, 870 грамм тәүлеклек үсеш алган “Симет” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте терлекчесе Хуҗина Гөлнара Әскадулла кызына;

- үзенә беркетелгән 83 баш терлектән 230 центнер тулаем, 895 грамм тәүлеклек үсеш алган “Шытсу” авыл хуҗалыгы предприятиесе” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте терлекчесе Нәбиуллина Рәзимә Васил кызына;

- үзенә беркетелгән 123 баш терлектән 356 центнер тулаем, 793 грамм тәүлеклек үсеш алган “Игенче” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте терлекчесе Рамазанова Гөлйөзем Мәхмүт кызына;

- үзенә беркетелгән 50 баш терлектән 177 центнер тулаем, 972 грамм тәүлеклек үсеш алган “Саба” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең “Мичән” бүлекчәсе терлекчесе Шәрипов Айдар Мәкъсут улына;

- “Нырты” авыл хуҗалыгы предприятиесе” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең баш агрономы Мөхәрләмов Инсаф Илсур улына;

- “Игенче” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең баш инженеры Әскаров Ильяс Энгелис улына;

- “Мөхәмәтшин З.З.” (крестьян) фермер хуҗалыгының ветеринария табибы Михайлов Юрий Николаевичка;

- “Шытсу” авыл хуҗалыгы предприятиесе” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең ветеринария табибы Гимадиева Мөршидә Тимершаех кызына;

- “Лукоз Саба” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең ветеринария табибы Сибгатуллин Ирек Миннебай улына;

- “Саба” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең “Сатыш” бүлекчәсе ясалма орлыкландыру технологы Юнысов Айрат Азат улына;

- “ТАТМИТ Агро” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең ясалма орлыкландыру технологы Нургалиев Булат Миннәхмәт улына;

- “Саба” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең баш бухгалтеры Кашапов Роберт Нәҗип улына;

- “Туган як” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең баш бухгалтеры Гилемханова Фәния Әхмәтзәки кызына.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов